КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 19 декабрь г.Казань № 1176

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2017 елга юридик затларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре чикләренә кадәр гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләрен тәэмин итүче электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, төзекләндерү һәм ремонтлау эшләрен үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2017 ел, 4 август, 551 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2017 елга юридик затларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре чикләренә кадәр гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләрен тәэмин итүче электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, төзекләндерү һәм ремонтлау эшләрен үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2017 ел, 4 август, 551 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 25 май, 395 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә, 1 пунктта “гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләрен” сүзләрен тиешле килешләрдәге «яки

комерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыклары алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар»ны сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2017 елга юридик затларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре чикләренә кадәр гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләрен тәэмин итүче электр челтәре хуҗалыгы объектларын төзү, төзекләндерү һәм ремонтлау эшләрен үткәрү белән бәйле чыгымнарын финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә:

исемендә, 1 пунктта, 12 пунктның бишенче абзацында “гражданнарның коммерциячел булмаган бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача берләшмәләре” сүзләрен тиешле килешләрдәге «яки комерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен, шулай ук 2019 елның 1 гыйнварына кадәр гражданнар тарафыннан бакчачылык, яшелчәчелек яки дача хуҗалыклары алып бару өчен төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар» сүзләренә алмаштырырга.

2. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин